Айдар Шиабиев
Ромель Маннапов

Яраттым мин сине Бәзәкә

Айдар Шиабиев Ромель Маннапов

Баян Вәлиевич Әхмеров

Тарихта калдырган эзләре

Бәзәкә, 2017 ел

Авторлардан

Советлар Союзы чорында эшләгән кешеләрнең күбесе ул заманнарны хәзерге чор белән чагыштырганда эше күп булды, акчасы аз булды дисәләр дә, элек яшәве күңеллерәк иде дип искә алалар. Киләчәккә өмет бар иде, эшләгән кешегә бушлай фатир, ял йортларына юлламалар бирделәр, кайларга гына барсаң да эш урыны булдырылды, хәерчелек бик нык кимеде, мәктәпләрдә, техникумнарда, ВУЗларда укып чыккан яшьләргә эшкә урнашып, гаилә корып, алга таба тагын да үзләренең тормышын яхшырту өстендә эшләргә мөмкинлекләр тудырылды. Үткәннәрне искә алмаган халыкның киләчәге юк дип тикмәгә генә әйтмәгәннәрдер инде күрәсең.

Бәзәкә авылының 500 еллык тарихында кемнәр генә ул авылда тумаган, кемнәр генә ул авылга килеп үзенең көчен түкмәгән. Шулар арасында 25 елдан артык тормышын Бәзәкә авылы, аның халкы белән бәйләгән Баян Әхмеров та бар. Ул җиде яшеннән туган авылыннан чыгып китеп, укып, районнар, авыллар буенча күченеп йөреп балаларга белем биргән кеше. Сугыш башланганчы ук Кызыл

Армия сафларына алынып, башыннан азагына кадәр көчен түгеп, сугыштан соң да күп еллар дәверендә илебезне аякка бастыруда катнашкан. Бу язманы Бәзәкә авылы кешеләре белән берлектә, Баян Вәлиевичның башкарган эшләрен искә алып, аны хөрмәтләү йөзеннән сезгә тәкъдим итмәкче булдык. Баян Вәлиевич турында истәлекләр һәм фотокарточкалар белән аның Менделеевск шәһәрендә яшәүче кызы Люция ханым уртаклашты.

Армиядә хезмәт иткән чорындагы материалларны табуда Россия Кораллы көчләре полковнигы Абдуллин Заһир Кәрим улына рәхмәтлебез. Хезмәтебезне басмага әзерләү чорында документларны җайга салу ягыннан Актаныш якларында туып үскән, хәзерге вакытта Әгерҗе шәһәрендә яшәүче Рушания Байтимеровага, безнең бу эштә теләктәшлек иткән һәркемгә олы рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Шиабиев А.А. Маннапов Р.З.

Балачагы, яшьлеге

1913 нче елны басудагы икмәкләрне исән-имин генә җыеп алып, амбарларны тутырган Күҗәкә авылы кешеләре кышлату чорында артык михнәтләр күрмичә генә язга чыктылар. Икмәкләр мулдан булганга күрә, абзардагы мал-туарлар да быелгысы елны башка еллар белән чагыштырганда көрерәк иделәр. Җылы яклардан кайткан кара каргалар, китмичә бу якларда яши торган кошлар белән бергәләп, әле кайчан гына, ат чанасы артыннан коелып калган мәкинәләрне чүпләп, ат тизәкләрен туздырып йөри иделәр. Алар да урамнарда күренми башладылар, ояларын корып, йомыркаларын салып бала чыгарырга утырдылар. Кошлар чүпләнергә, тамак туйдырырга кардан ачылган басуларга күчтеләр. Басулардан пар күтәрелә башлады. Бүген-иртәгә басуга чыгабыз, тырмага төшәбез дигәндә генә себер яктан салкын җил исеп, карлы яңгыр ява башлады. Бөреләре ачылып, яфраклары күренә башлаган каен

агачларының өсләренә төшкән кар бөртекләре, яфракка төшкәч эреп суга әйләнеп җир өстенә тамдылар.

Габделвәли бай бүген төнлә юньләп йоклый алмады. Әллә ниткән төшләр күреп бетерде. Таң алдыннан хатынының ыңгырашкан тавышына уянып киткәч, тиз генә урыныннан торып, хатыны яткан караватянына килде. Акрын тавыш белән “Башландымы әллә” – дип сорау бирде. “Әйе” дигән тавыш ишетүгә, ике ишек аша күрше бүлмәдә йоклап яткан ялчы хатын бүлмәсенең ишеген ачып, “Бар, әбиләрне чакыр” – дип әмер бирде. Ялчы хатын байбикә янында төн саклап утырганда, стенадагы сәгать уникене суккач, байбикә аны үзе “Бар, минем хәлем ярыйсы әле, тиз генә булмас ахрысы” – дип ял итәргә җибәргән иде. Өстендәге киемнәрен чишенмичә генә яткан ялчы хатын тиз генә башына шәлен каплады да, урамга чыгып йөгерде. Габделвәли өс киемнәрен киенеп алды да, мич плитәсе янына килде. Әзерләп куйган коры утын пүлинәләрен әле сүнеп тә җитмәгән плитә эчендәге кызыл күмерләр өстенә ташлады да, кысыбрак куйган юшкә тимерен үрелеп ачты. Хатыны янына килеп, кулын аның маңгаена куйды.

Хатынның маңгаеннан тир бәреп чыккан иде. Озак та көттермичә байбикәнең бәбилисен белеп, көтеп торган хатыннар өй эченә килеп керделәр. Габделвәли өске киемнәрен киеп, кулына колакчан бүреген тотып урамга, ишек алдына чыгып китте. Чит хатыннар кергәндә ачылган капка тавышына өрә башлаган этләр, хуҗаларын күрүгә тып-тын калып, койрыкларын болгап, иркәләнеп җиргә яттылар. Шул вакытны хуҗалыкны төннәрен каравыллаучы ялчы “Нинди боерык булыр икән?” – дип хуҗасы янына килеп басты. Габделвәли: “Бар, ике чиләк су алып кер дә, плитә өстенә куй” – дип әмерен бирде дә, сибәләп яуган яңгырдан чыланмыйм дип, ачык лапас эченә кереп китте. Лапас эчендә ике ат арбасына, чәчүгә чыгарга дип әзерләп төяп куелган тырмалар, бәллүкләрне күз йөртеп чыкканнан соң, стена кырындагы утын әрдәнәсе янындагы бүкәнгә барып утырды.

Бай Әмир малае Габделвәлинең даны, булдыклылыгы, әле яшь булуга карамастан, акыл белән эш итә белүе, яңалыкларны тиз үзләштереп, беренчеләрдән булып тормышка ашыра белүе, шуның аркасында аз чыгымнар тотып, күп файда чыгара торганлыгы белән, Актаныш төбәгендә генә

түгел, еракларга таралган иде. Менә хәзер дә, булган буш вакыттан файдаланып, үзенең башлаган эшләренә анализ ясарга кереште.

Столыпинның “җир реформасын” төрле кеше төрлечә кабул итте. Барып чыга торган эш түгел ул, диючеләр дә табылды. Кайсы бер кеше тотынырга курыкты, үз көченә ышанмады. Кайберәүләр Столыпинны атып үтергәч, башлаган эшләрен ташлап, искечә эшли башладылар. Габделвәли андыйлардан түгел шул. Закон бер чыккач эшләргә тиеш икәнен ул бик яхшы белә. Дәүләт недоимкадан азат итә икән, байлык янга кала, атлар белән башкара торган эшләрне, агрегатларын техникага алыштырсаң, эшең тизрәк барачак, сыйфатлырак булачак, тагын байлык артачак. Үз башы белән аңламаган кешегә, күпме генә әйтсәң дә керми шул. Картлар әйтмешли: ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән керми. Кайбер зирәгрәк кешеләр соңгы вакытларда Габделвәлинең эшләрен күзәтеп, ул нишләсә, шуны эшләргә маташтылар. Әмма ләкин, күбесенең эшләре барып чыкмады. Нигә дисәң, түземлелек җитмәде, башка сәбәпләр булды. Үз-үзеңнән дә акыллырак булып булмый шул. Бай булу

өчен тырышып эшләү генә җитми, баш та эшли белергә тиеш.

Шулай уйланып утырганда, абзардагы малларны ашатырга дип ялчылар килеп җиттеләр. Кисәк кенә яңгыр туктады, күк йөзендә кояш күренде. Ыгы-зыгы килеп өй ишегеннән кереп-чыгып чабаланган хатыннар артыннан берзаман елаган шикелле яшь бала тавышы килде. Габделвәли ишеккә таба юнәлде, кендек әбисе чыгып: "Тагын бер малаең булды" – дип Габделвәлине котлады. Габделвәли бала исән-имин туып, анасы әйбәт кенә котылса дип, алдан хәстәрләп куйган күчтәнәчләрен өйалды эчендәге шкафтан алды да, хәбәр биргән карчыкка һәм башка булышкан хатын-кызларга рәхмәтен әйтеп башка бәйли торган яулыклар, чүпрәк-чапракларны өләшеп чыкты. 1914 нче елның 19 апрелендә Габделвәли гаиләсендә икенче малай туды. Малай туу ир-ат кешегә шатлык инде ул. Киләчәктә өмет, булышчы дигән сүз. Дөньяга килгән малайга Фәтхелбаян дигән исем куштылар. 19 апрельдән 28 июльгә кадәр җитмеш көн бар иде әле. Җитмеш көннән соң Беренче Бөтендөнья сугышы башланды.

Фәтхелбаянга Беренче Бөтендөнья сугышын, 1917 нче елның февраль һәм октябрь революцияләрен, 1918-20 еллардагы гражданнар сугышларын кечкенә килеш аңламыйча үтәргә туры килсә дә, алга таба аны тагын да авыррак заманалар читләтеп үтмиләр. 1921 еллардагы ачлык Минзәләдә белем алган Фәтхелбаянга, абыйсы Миргалимгә дә гомергә онытылмаслык вакыйгаларның берсе булып кала.

1923 нче елны башланган яңа экономик политика укыту системасына да үтеп кереп, башларны әйләндереп бетерә.

1928-1929 еллардагы колхозлашу чорында балигъ булмаганлыктан алар катнаша алмыйлар.

1932 нче елларда кулакларны сөргенгә сөргәндә, 1936-37 елларда репрессия вакытларында Фәтхелбаян да, Миргалим дә мәктәпләрдә укыта торган булалар. Коммунистлар партиясе күрсәткән юлдан читкә чыкмыйлар.

Бай Габделвәли революциядан соң раскулачивание дигән зәхмәтләр кузгалганчы, акыллы фикерләргә колак салып, барлык сатардай милкен сатып бетерә, ике катлы йортын Суыксуга сата. Акча, алтын-көмешне җиргә күмә. Соңрак бу

байлыкларны башка бер кеше табып алган дип сөйлиләр. Габделвәли бай авыл халкына да ярдәм итә. Шуңа авыл халкы аны бик ихтирам белән искә алып сөйли. Раскулачивание вакытында ул авылдан сөрелми, читкә китә. 1932 елны аны кулга алып, төрмәгә алып китәләр. Ул төрмәдән башка кайтмый.

1921 нче елны Фәтхелбаянны Минзәләгә тугыз еллык укытучылар әзерли торган мәктәпкә бирәләр. Ул елларны бөтен Идел буе халкы ачлыктан тилмерә. Минзәләдә укый торган балалар да ачлыктан интегәләр. “Бик нык ашыйсы килгәндә Минзәләдән чыгып, Актаныш юлына басып сәгатьләр буе Актаныш ягыннан берәр кеше килеп, бер телем икмәк бирмәс микән дип көтеп тора идек” – дип сөйли Фәтхелбаян. “Ачлыктан интегеп, эчне тотып җиргә ятып елаган чаклар да бер генә тапкыр булмады” – ди. Минзәлә мәктәбендә укый башлагач классташлары, иптәш малайлары Фәтхелбаян сүзе озын, әйтергә уңайсыз дип, аны Баян гына дип атый башлыйлар. Алга таба барлык документларда да Баян исеме генә языла. Баян, укытучылар мәктәбен гел яхшы билгеләренә генә тәмамлагач, 1931 елның сентябрь аенда, аны Красный бор районы Салагыш мәктәбенә укытучы итеп җибәрәләр. Салагыш

авылы Иж елгасы белән Кама елгасының кисешкән урыныннан ерак түгел кара урманнар эчендә урнашкан була. Бүгенгесе көннәрдә дә 40 чакрым урман аша үтмичә анда барып җитеп булмый. Хәзерге вакытта Минзәләдән Салагышка барып җитәр өчен 200 чакрым җир үтәргә кирәк. Баянны Минзәләдән атка утыртып турыга Кама ярына кадәр алып баралар да, паром белән Красный бор ягына чыгаралар. Красный борда аның документларын тикшергәннән соң, кулына приказ тоттырып, Салагыш ягына кайта торган кешеләргә ияртеп җибәрәләр. Баян аркасына аскан капчыгы белән җәяүләп Салагыш авылына килеп җитә.

Салагыш мәктәбен 1910 нчы елны татар халкының танылган драматургы Юныс Әминевның бабасы Садыйк Әминев үз акчасына төзеткән була. Алабуга өязендә урнашкан Салагыш авылында рус-татар земство мәктәбе ачыла. Беренче директоры итеп һәм рус телен укытырга дип Юныс Вәлидовны җибәрәләр (Красный бор районы Балтач авылы кешесе). Февраль, октябрь революцияләре чорында Юныс Вәлидов Алабугада, Казанда барган революцион-сәяси күтәрелешләрдә актив катнаша, 1918 елда большевиклар партиясенә керә. 1918-1919

елларда Алабуга өязендә мөселман эшләре комиссариаты рәисе булып тора. Колчак гаскәрләре Алабугага якынлашкач, Юныс Казанга китә һәм гражданнар сугышы елларында мөселман хәрби коллегиясендә хезмәт итә.

Ул – Татарстан Республикасын төзүдә катнашкан дәүләт эшлеклеләренең берсе. Татарстан Республикасы оешканнан соң, 1920-1924 елларда, Татарстан АССР хөкүмәтендә җир эшләре халык комиссары була. Мәскәүдән эшелон белән 1921 нче елны икмәк алып кайтып, Татарстан халкын ачлыктан коткаручы да ул. Юныс Вәлидов Мирсәет Солтангалиевның якын дусты була, аның белән тыгыз элемтәдә тора, һәм ахырдан “Солтангалиевчылыкта” гаепләнә. Баян Әхмеров менә шул Юныс Вәлидов укыткан мәктәпкә, укытырга дип, Салагыш авылына килеп җитә. Халыкка Юныс Вәлидов турында дөрес хәбәрне җиткермиләр. Аны 1925 нче елны Мәскәүдә Семашко больницасында юкка чыгаралар.

1931 нче елны Баян Салагышка килеп кергәндә 700 хуҗалыгы булган Салагыш авылының яртысы янып беткән була, 1910 нче елны төзегән мәктәп тә яна, янгыннар 1930 нчы елны да булган

була. Красный борга бара торган юл өстендә укытырга яраклы бер йорт табып ШКМ (Школа крестьянской молодежи) ачып җибәрәләр. Мәктәпкә укытырга барганда, мәктәптән калган хәрабәләр өстенә басып йөргәнгә, аяк киемнәре һәрвакыт корым гына була иде, дип сөйли Баян. ШКМ мәктәбенә укырга якын-тирәдәге авыллардан яшьләрне җыялар. Мәктәпнең үзенең җире, сыерлары, яшелчә бакчасы була. Укучылар җәйләр буе шул җирдә эшлиләр, үзләренең ашханәләрен булдыралар, юынырга мунча ясап куялар. Беренче чыгарылышта 18 укучы була. Беренче директор булып Шаршады авылыннан Ханнанов Шәех дигән кеше килә. Салагыш мәктәбендә укыта башлагач, укучылар арасында Баян дигән исем Баян Вәлиевичка әйләнә. Баян Вәлиевич мәктәптән тыш, якын-тирә авылларда агитация, культура-масса эшләре белән шөгыльләнә башлый, иртә таңнан караңгы төнгә кадәр авылдан-авылга йөреп үткәрә. Башка авылларда да ШКМнар ача башлыйлар. Яшь укытучы, кайда кушсалар, шунда бара. Баян Вәлиевич йөреп укыткан авылларның берсе – табигатьнең бик матур җирендә урнашкан шәм шикелле басып торган йөзәр еллык наратлар

арасында, тау башында салынган Татар Шаршадысы дигән авыл була. Авылның аскы өлешендә алпавыт ясаткан бик матур күл, күлнең аргы ягында икенче тау башында алпавыт Шәех-Алинең гаҗәеп матур “Ак сарае” була. Шәех-Али Кавказда Россиягә каршы көрәшкән имам Шамилнең малае. Имам Шамилны сугыш вакытында кулга алгач, аны малайлары белән Петербургка алып кайталар. Патша Александр II аларны гафу итә. Шәех-Али бик тә батыр сугышчы була. Башкорт-мишәрләр белән берлектә төрекләргә каршы көрәшә. Патша аны орденнар белән бүләкли. Төрле сәбәпләр аркасында Шәех-Али Казанга килеп чыга. Казанда морза Сәетгәрәй малайлары белән дуслаша, аларның сеңелләренә өйләнә. Сәетгәрәй кызы өчен бик күп бирнә бирә, һәм Шәех-Али шуның нигезендә Шаршадыга килеп урнаша, патша армиясендә генерал-майор дәрәҗәсенә җитә.

Баянның Минзәләдә укыган чагы (ак гимнастеркадан)

Шаршада мәктәбенең урнашкан урыны.

Мәктәп астындагы күл

Шаршада авылында Шаех-Али йортының калган бер күренеше.

Балтач авылында Баян белән Бәдәрнең язылышкан урыны колхоз идәрәсе һәм авыл советы урнашкан йорт. 1933 ел.

Баян Валиевичнең Алабуга районында мәктәптә эшләгән вакыты. 1935 ел. (икенче рәттә сулдан беренче)

Баян Валиевичнең Алабугада РОНОда эшләгән вакыты. 1938 ел. (уңда беренче)

71

Копия.

НАРОДНЫЙ КОМИССАРИАТ ВНУТРЕННИХ ДЕЛ СССР.

Отдел Актов Гражданского состояния

Т А С С Р.
Исполнительный Комитет
БАЛТАЧЕВСКОГО
Сельского совета
депутатов трудящихся
Красноборского р-на

май 1933года

с. Балтач.

СВИДЕТЕЛЬСТВО О БРАКЕ:

№ 2.

Гр. АХМИРОВ
Баиян Валиевич

Гр-ка НАСИКОВА
Бадар Габдрахмановна

Вступили в брак, о чем в книге записей актов гражданского состояния о браке произведена соответствующая запись
Тысяча деведсод тредсает третего май м-ц

АХМИРОВ — НАСИКОВА
/он/ фамилии после заключения брака /она/

Зав. бюро Загс подпись

Делопроизводитель –

1948 г. Декабря 16 дня я, Государственный нотариус 1-ой нотариальной конторы гор. Уфы Башкирской АССР Кашаев, свидетельствую верность настоящей копии с подлинником ее

при сличении настоящей копии с подлинником в последнем подчисток, приписок, зачеркнутых слов и иных особенностей не оказалось. Взыскано 2 руб. единой

По РЕЕСТРУ № 48682

Ст. нотариус

Бондюк районы Абалач мәктәбендә укыган вакыты.
1938 ел.

Абалач мәктәбендә директор Баян Валиевич
укытучылар коллективы белән
(уң якта икенче рәттә беренче) 1938 ел.

“Ак сарайны” 1927 нче елны җидееллык мәктәпкә әйләндерәләр. Тора-бара ШКМга әйләнә. Баян Вәлиевич Шаршады авылында яшьләргә белем бирә башлый. Төрле авыллардан килгән яшьләр арасында Балтач авылыннан килгән укучылар да була. Шуларның берсе Нәҗип Әхмәтгәрәй улы Әминев. Алга таба ул Красный бор районы газетасында эшли, озак еллар аның редакторы булып тора. Балтач авылыннан килгән икенче бер укучысы Баян Вәлиевич белән бер елны туган Насикова Бәдәр дигән кыз була. Шулай бер вакыт дәресләр беткәч, Бәдәр кибеткә кереп үзенә кирәк-яраклар алганда, кибеткә Баян Вәлиевич килеп керә. Укытучысын күргәч Бәдәр каушап кала, кулыннан кибеттә сатып алган әйберләре төшеп китә. Баян Вәлиевич чүгәләп төшеп киткән әйберләрне җыярга булыша. Кибеттән чыкканнан соң, көлешә-көлешә үзара сөйләшә башлыйлар, якынрак танышалар. Баян Вәлиевичка да, Бәдәргә дә ул вакытта унсигез яшь була. Яшьләр арасында мөнәсәбәтләр барлыкка килә. Шул вакытлардан соң Баян Вәлиевич Балтач авылына җәяүләп, Балтач авылы алпавыты Ибраһим Халитов салдырган ак күперләр аша Бәдәрне озатып

йөри башлый. Бәдәрнең әнисе Хәнифә апа белән, аның туганнары белән таныша. Бәдәрнең әтисе Насиков Габдрахман бер ел элек кенә, 1931 нче елны вафат булган була. Баян белән Бәдәр арасында мәхәббәт утлары кабынгач, алар бергәләп тормыш корырга уйлыйлар. 1933 нче елның 5 маенда Баян белән Бәдәр Балтач авылы Советында язылышалар. Язылышу тантанасында Балтачта авыл Советы рәисе булып эшләүче кеше – Бәдәрнең бертуган абыйсы Насиков Габделнур Габдерахман улы була. Ул яшьләргә бәхет теләп, аларны озатып кала. Насиков Гаделнур сугышның беренче көннәрендә ук фронтка китеп, шунда ятып кала. 1933 нче елның көзендә Баян Вәлиевич белән Бәдәр Габдрахмановна күченеп Алабуга районына эшкә китәләр. Алар киткәч, 1934 нче елны Шаршады мәктәбен тулы булмаган урта мәктәпкә әйләндерәләр. Беренче укытучы булып үзгәртелгән мәктәпкә Барҗы авылыннан Гайнуллин Рифкать дигән кеше килә. Сугыш башлангач, сугышка китеп полковник дәрәҗәсенә җитә. Сугыштагы батырлыклары өчен өч Дан ордены белән бүләкләнә. Сугыштан соң пенсиягә чыкканчы Алабуга укытучылар институтында студентларга

белем бирә, Балтач авылы кызына өйләнә. 1933-1937 елларда Баян Вәлиевич белән Бәдәр Габдрахмановнага Алабуганың үзендә һәм Алабуга районы мәктәпләрендә эшләргә туры килә. Бәдәр Габдрахмановна үз өстендә эшләп, укытучы таныклыгы алып, мәктәптә башлангыч сыйныфларны укыта башлый. Яшь укытучылар авыл кешеләре арасында агитация белән шөгыльләнәләр, бригадага оешып концертлар куеп йөри башлыйлар. 1934 нче елны аларның малайлары туа, аңа Роберт дигән исем кушалар. 1935 нче елны Баян Вәлиевич читтән торып Казанга укытучылар хәзерли торган институтка кереп, анда белем ала башлый. Шул елларны аны мәгариф системасына күчерәләр, инспектор булып эшли башлый. 1937 нче елның азагына имтиханнарны яхшы билгеләренә генә тәмамлап, укыту эшен дәвам итә. 1938 нче елның башында аны укытырга Абалач мәктәбенә җибәрәләр, алар гаиләләре белән шул авылга күченеп киләләр. Абалач мәктәбендә укытучы, директор булып 1939 нчы елның октябренә кадәр Баян Вәлиевич һәм Бәдәр Габдрахмановна эшләүләрен дәвам итәләр.

Сугышта һәм хәрби хезмәттә.

1940 нчы елның 1 февралендә Баян Вәлиевичны Кызыл Армия сафларына алалар. 25 февраль көнне присяга кабул итә. Киев округының 146 нчы стрелковый девизиясенең 608 нче стрелковый полкында рядовой солдат булып хезмәт итә башлый. Присягадан соң, сержантлар мәктәбендә укытып сапер-кызылармеец итәләр. 1941 нче елның 15 мартында аны отделение командиры итеп билгелиләр. Баян Вәлиевич Киев сугышчан округының көньяк-көнбатыш фронтының 6 нчы армиясенә буйсынган, 4 нче танк корпусы, 8 нче танк девизиясенең 8 нче мотострелковый полкында хезмәт итә башлый. 22 нче июнь көнне Киевны бомбага тоттылар, безгә хәбәр иттеләр: иртәнге сәгать дүрттә сугыш башланды, дип әйтелгән җырның мәгънәсен Баян Вәлиевич үз күзләре белән күреп, үз җилкәсендә татыган кеше. Сугышның башланган беренче көненнән үк Баян Вәлиевичка немец фашистларына каршы торырга туры килә. Сапер дигә сүзнең

мәгънәсе яшерелгән миналарны юкка чыгаручы яисә миналарны яшереп куя белүче кешене аңлата. Немецлар сугышның башланган чорында безнең гаскәрләрне кысрыклап Мәскәү янына кадәр чигенергә мәҗбүр итәләр. Саперларга көннән-көнендә ике ут эчендә булырга туры килә. Безнең гаскәрләр артка чигенгәндә дошман гаскәрләрен тоткарлау өчен саперларга фронтның утлы сызыгында булып, күпмесенә шунда ятып калырга туры килде икән? 1942 нче елның 15 январендә Баян Вәлиевичны взвод командиры итәләр. Яңадан ике ай үтүгә 25 мартка ул инде саперлар ротасын җитәкли башлый. Шул көннәрдә Баян Вәлиевичка кече лейтенант чины бирелә. Сугышта иң күп югалтуларга дучар булган сугышчылар арасында саперлар һәм элемтәчеләр була. Алга таба барганда да, артка чигенгәндә дә саперларны һәм элемтәчеләрне снайперлар ябалак тычкан күзләгән шикелле күзләп, юк итеп торганнар. Башка төр гаскәрләрдә хезмәт итүче сугышчылар блиндажларда, траншеяларда, окопларда үзләрен саклабрак сугышканда, саперлар ачык, тип-тигез урыннарда миналар куярга мәҗбүр булганлыктан, алар бик күп югалтуларга дучар булалар. Солдатлар

арасыннан сапер хезмәтенә сайлап алганда, кешенең психикасын, түземлелеген, белемен, башы эшләвенә нык игътибар иткәннәр. Теләсә кайсы кешедән сапер ясап булмый, “сапер бер генә тапкыр хата ясый” дигән сүз тиккә генә әйтелмәгән. Сапер булыр өчен солдатларны укытырга да шактый вакыт кирәк була. Кызыл Армия кораллы көчләрендә булган төп миналарның барысын да җентекләп өйрәнүдән тыш, саперлар дошман кораллы көчләре миналарының схемасын, техник яктан булган барлык серләрен белергә тиеш булалар. Дошман миналар ясау буенча алга киткән була. Җитмәсә вакыты-вакыты белән үзгәрешләр кертеп тора. 1942 нче елның 15 январендә Баян Вәлиевич взвод командиры булса, 1942 елның 15 маенда аны батальон командирының ярдәмчесе итеп билгелиләр. 1942 нче елның 29 июнендә сугышта күрсәткән батырлыклары өчен кече лейтенант Әхмеровка лейтенант чины бирәләр. 8 август көнне каты сугышлар барганда Баян Вәлиевич яралана. Шул көнне күрсәткән батырлыклары өчен аңа “За отвагу” медален тапшыралар.

Капитан Ахмеров 3.

ВОЕННАЯ ПРИСЯГА

Я, гражданин Союза Советских Социалистических Республик, вступая в ряды Вооруженных Сил, принимаю присягу и торжественно клянусь быть честным, храбрым, дисциплинированным, бдительным воином, строго хранить военную и государственную тайну, беспрекословно выполнять все воинские уставы и приказы командиров и начальников.

Я клянусь добросовестно изучать военное дело, всемерно беречь военное и народное имущество и до последнего дыхания быть преданным своему Народу, своей Советской Родине и Советскому Правительству.

Я всегда готов по приказу Советского Правительства выступить на защиту моей Родины — Союза Советских Социалистических Республик и, как воин Вооруженных Сил, я клянусь защищать ее мужественно, умело, с достоинством и честью, не щадя своей крови и самой жизни для достижения полной победы над врагами.

Если же я нарушу эту мою торжественную присягу, то пусть меня постигнет суровая кара советского закона, всеобщая ненависть и презрение трудящихся.

ПОДПИСЬ Ахмеров

Звание Красноармеец

Имя, отчество и фамилия Басир Валеевич Ахмеров

Наименование части, управления, учреждения 608-й стрелковой полк

23 февраля 1944 г.

Зак. 533

Баян Валиевичның Кызыл Армия дә беренче көннәре.

Капитан Ахмеров

Майор Ахмеров (уңда беренче)

Малае Ахмеров Роберт Баянович
(уртада) 1956 ел.

Министерство Обороны Союза ССР

2-й экземпляр.

ПОСЛУЖНОЙ СПИСОК

АХМЕРОВ

(фамилия)

Баян Валеевич

(имя и отчество)

Воинские звания	Дата и номер Постановления Совета Министров (СНК) СССР. Дата и номер приказа по личному составу и чей приказ	Воинские звания	Дата и номер Постановления Совета Министров (СНК) СССР. Дата и номер приказа по личному составу и чей приказ
1. Мл.лейтенант	25.03-1942г. № 0107/3	6.	
2. Лейтенант	29.06-1942г. №018/п 6рез.арм.ЮЗФ	7.	
3. Ст.лейтенант	15.09-1942г. №0128/п 60 Арм.	8.	
4. Капитан	21.10-1947г. №1430 МВД	9.	
5. Майор	2.01-1952г. № 2 МВД СССР	10.	

Удостоверение личности:

Серия ГК № 32241 Дата выдачи 15.I-54 | Серия № Дата выдачи

В/билет Серия АЗ № 20778 Дата выдачи | Серия № Дата выдачи

Серия № Дата выдачи | Серия № Дата выдачи

Серия № Дата выдачи | Серия № Дата выдачи

Составлен 30 декабря 1955 г.

в 9 дорожно-строительной дивизии ОДСК

(наименование части)

на основании старого послужного списка и личного дела.

(указываются документы)

16. Правительственные и другие награды

а) Какими орденами и медалями СССР, Союзных республик или иностранных государств награжден, когда и за что.

Наименование орденов и медалей, а также, за что награжден им (за боевые отличия, за выслугу лет в ВС и т. д.)	Кем награжден	Даты указов и приказов или актов о награждении и их №№
Медаль "За победу над Германией"	Указ Презид. Верх.Совета СССР	9.5-1945г.
Медаль "За победу над Японией"	- " -	30.9-1945г.
Медаль " За отвагу"	6 Арм.	№ 062 от 24.9-42г.
Медаль "30 лет Советской Армии и флота"	Указ Презид. Верх.Совета СССР	22.2-1948г.
Медаль "За боевые заслуги" за выслугу лет	- " -	30.1-1951г.
Орден "Красной Звезды" за выслугу лет	- " -	5.11-1954г.

1942 нче елның 8 августында аны санитар поезды белән эвакогоспитальгә Караганда шәһәренә җибәрәләр. Баян Вәлиевич госпитальдә 1942 нче елның 4 ноябренә кадәр дәвалана. Госпитальдә ятканда, 15 сентябрь көнне аңа өлкән лейтенант чины бирәләр. Терелеп чыкканнан соң, Урта-Азия сугышчан округының юллардан файдалану батальонына комендант ротасының командиры итеп җибәрәләр. 1943 нче елның 5 нче декабренә кадәр ул шул хезмәтне башкара.

1945 нче елның 9 май – Җиңү көнендә Баян Вәлиевич Полтава өлкәсендә тыл җитәкчесенең вәкаләтле кешесе була. 1945 нче елның 25 августыннан соң Баян Вәлиевичны күперләр төзү буенча рота командиры итеп билгелиләр. 1946 нчы елның 27 мартында укытучы кешене полк мәктәбенең җитәкчесе итәләр, һәм ул алдагы елларда армия өчен сержантлар, кадрлар әзерләү белән шөгыльләнә. 1947 нче елның 21 октябрендә СССР Эчке эшләр министрлыгы приказы (1930) белән аңа капитан чины бирәләр.

1948-1952 нче елларда хуҗалык эшләре белән шөгыльләнә торган ротаның командиры була. 1952 нче елның 2 январендә Баян Вәлиевичка майор чины бирелә (СССР Эчке эшләр министрлыгы приказы белән). 1952-1954 нче елларда хуҗалык белән җитәкчелек итә торган ротаның командиры була. 1954-1956 нчы елның 23 ноябренә кадәр батальон командирының кирәк-яраклар белән тәэмин итү буенча ярдәмчесе була. 23 ноябрьдә хезмәт срогы тулу сәбәпле аны запаска җибәрәләр.

Баян Вәлиевичны 1940 нчы елны Кызыл Армия сафларына хезмәт итәргә алгач, беренче көннәрен Бергичев шәһәрендә башлый. Сугыш башланган көннәрдә ул Львов шәһәре тирәсендә була. 1941-1942 нче елларда фашистлар белән көньяк-көнчыгыш фронтында сугыша. 1942 нче елның азагында аңа каты сугышларда Воронеж фронтында булырга туры килә. Алда әйтелгәнчә, яралангач эвакогоспитальгә Караганда шәһәренә җибәрелә. Баян Вәлиевич берничә тапкыр яралана. Яралары артык зур булмаганлыктан, санчастьләрдә ятып дәваланырга туры килә. Снаряд кыйпылчыгы тиеп тә, пуля тиеп тә калдырган эзләре була. Эвакогоспитальдән терелеп чыккач, аны

Төрекмәнстанга Кызыл Ата шәһәренә җибәрәләр. Анда резерв армиясе туплыйлар. 1943-1945 нче елларда Полтава шәһәре тирәсендә сугыш вакытында җимерелгән объектларны торгызу белән шөгыльләнә. Сугыштан соңгы елларда Уфа шәһәрендә хезмәт итә. Уфадан Новгород шәһәренә күчерәләр. Новгород шәһәренә күчеп киткәндә, аларның Роберт дигән уллары Уфа шәһәрендә калган була. 1934 нче елны туган Роберт әти-әнисе белән төрле авылларда, шәһәрләрдә, хәрби шәһәрчекләрдә яшәп үсеп җиткәч, Уфа шәһәрендәге урман-техника институтына укырга кереп, аны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган була. Габделвәли бабайның оныгы Әхмеровлар династиясен алга таба югары үрләргә күтәрердәй егет булып үсеп җитә. Институтта укый башлаганчы, кайсы гына мәктәпләрдә укымасын, ике укытучы гаиләсендә туып үскән малай һәрвакыт яхшы билгеләренә генә укый, бик тә талантлы бала була. 22 яшьлек Роберт 1956 нчы елны әти-әнисе янына кунакка килә. Новгородта кунак булганнан соң, Мәскәүне күрәсе килеп, Мәскәүдә яшәгән туганнары янына китә.

Мәскәүдә кунак булып, шәһәрдә булган музейларны, метроларны, кибетләрне карап йөргәннән соң, кире Уфага кайтырга дип билет ала. Туганнары Робертны поездга озатырга чыгалар. Сөйләшеп-көлешеп торганда, вокзалда поезд килә, дигән хәбәр бирәләр. Килә торган поездга тимер күпер аша чыгарга кирәк була. Роберт яшьлеге белән үз-үзенә ышанычы, күрәчәге булгангамы, тимер күпер аша чыкмыйча перроннан поездлар юлына сикереп төшә. Озата килгән апасы күпме генә артыннан: “Анда барма, барма” – дип кычкыруына карамастан, апасының сузенә колак салмыйча, рельслар аркылы баруын дәвам итә. Роберт күзләрен килә торган поездга төбәгән була, рельслар аркылы чыга торган кешене күргәч, тепловоздагы машинист кычкырта башлый. Көтмәгәндә каршы яктан икенче поезд килеп чыга, ул поездның да машинисты кычкырта башлый. Роберт ул поездны күрми, машинистлар икесе дә экстренно тормозларга басалар, әмма ләкин соң була инде. Роберт фаҗигале төстә вафат була. Аны Мәскәүдә Даниловский дип аталган зиратта җирлиләр. Баян Вәлиевич белән Бәдәр Габдрахмановнаның шул вакытларда булган

кайгыларын язарга сүзләр табып булмый. (Берегезгә дә андый хәлләрне күрергә язмасын).

Яраттым мин сине, Бәзәкә

Баян Вәлиевич хәрби хезмәттән туктагач, гаиләсе белән Бондюг шәһәренә кайта һәм икенче номерлы мәктәптә балаларга физика фәнен укыта башлый. 1958 нче елны партия тәкъдиме белән утызмеңчеләрнең берсе булып Сталин исемендәге колхозга (Бәзәкә авылына) рәис итеп җибәрелә. Ул елларда колхоз-совхозларда эшләрне оештырганда һич кенә дә партия съездларның карарларына таянып эшләмичә булмый торган чак. Пленумнар, партия конференцияләре төп рольләрне уйныйлар. 1956 нчы елны Мәскәүдә узган КПССның XX съезды материаллары нигезендә эшли башлаган Баян Вәлиевичка, 1959 нчы елның 27 январеннән 5 февраленә кадәр барган КПССның XXI чираттан тыш съезды билгеләгән, халык хуҗалыгын үстерү буенча 1960-1965 елларга багышланган экономика өлкәсендә бик зур мәсьәләләрне хәл итәргә туры килә. 1959 нчы елда Сталин колхозы эреләндерелә. (“Ык тамагы”, “Труженик”, “Сәйтәк”, “Игенче”,

“Татар Тәкәше”, “Беренче май”, “Мари Тәкәше”, “Кызыл Октябрь” хуҗалыкларын Бәзәкәгә кушалар.

17 ел Армиядә приказга буйсынып, приказ биреп эшләгән майорга авыл хуҗалыгында, җитмәсә берләштерелгән зур хуҗалыкта эшләп китеп, беренче адымнар ясавы җиңел булмый. Баштагы чорда ул үзе янына үзе кебек сугышта булган кадрларны тупларга тырыша. Алар белән бер-берсен аңлап эшләве җиңелрәк була. Әмма ләкин, алга партия куйган бурычларны тормышка ашыру өчен, хуҗалыкның экономикасын күтәрергә укыган, белемле яшь кадрлардан башка киләчәктә эшләп булмаячагын тора-бара үзе дә аңлый башлый. Яшь кадрлар кирәклеге бигрәк тә 60-нчы еллар башында сизелә. Ул елларда колхозларда башкарган эшләр өчен хезмәт көне белән түли торган булалар. 1961 нче елны илебездә яңа акчалар барлыкка килә. Бондюг, Әгерҗе, Красный бор районнарын Алабуга районы белән берләштерәләр. Колхозларда эшләнгән эшләргә акчалата түли башлыйлар. 1956 елны КПССның XX съезды Сталинның культын фаш иткәннән соң гына, 1961 нче елны 47 яшендә Баян Вәлиевичны Коммунистлар партиясе сафларына кабул итәләр.

Бәзәкә халкы Баян Вәлиевич колхозга рәис булып килгәч, аның эшләгән эшләре турында менә болайрак дип сөйли: Хуҗалыкның мактарлык урыны юк иде, бер хезмәт көненә нибары 15 тиен түләнде. Яңа килгән җитәкче эшне шуннан башлады, колхозчының тормыш дәрәҗәсен күтәрергә, аларга үз көчләренә ышаныч тудырырга, аннан инде таләп итәргә була, дип уйлады ул. Баян Вәлиевич кешеләр күңеленә ачкыч таба белде. Үзе дә тәртип, төгәллек һәм дисциплина яратты. Башкаларны да шуңа өйрәтте. Коллектив белән бик тиз уртак тел тапты. Әкренләп колхоз көч җыйды һәм үсте. Тора-бара күрше авыллар да кушылды. Колхоз белән җитәкче дә үсте. Өлкәннәрнең киңәше крестьян хезмәтен дөрес оештырырга, тәҗрибә тупларга ярдәм итте.



“Кама” колхозының идәрә йорты. 1980 ел.



Баян Валиевич кабинетында эш өстәле артында. 1980 ел.

Баян Валиевич Бәзәкә мәктәбендә.

Баян Валиевич мәктәптә укучылар белән очрашу.

Рәис һәрвакыт авылның абруйлы картлары ярдәменә таянды. 1961 нче елда ук хезмәт көненең бәясе 3 сумга күтәрелде. Өстәвенә эшләгән акчаларын колхозчылар үз кулларына ала башладылар, акчалата түләү кертелде. Намус белән эшләргә кирәк икәнен һәркем аңлады. Колхозчылар көчләрен дә, вакытларын да кызганмадылар, һәрнәрсәдә рәискә булышырга тырыштылар. Аның колхозчылар өчен тырышуын аңладылар. Колхозның машина-трактор паркы танымаслык булып үзгәрде. Яңа тракторлар, комбайннар, авыл хуҗалыгы машиналары белән тулыланды. “Кама” колхозында хатын-кызларның беренче трактор бригадасы эшли башлады. Бригадага рәис һәрвакыт ярдәм итте. Районда бердән-бер булган куян асрау комплексы да “Кама” колхозында барлыкка килде. Баян Вәлиевич зур сабырлык белән белгеч кадрлар үстерде. Моңа резервны авыл мәктәбеннән алды. Урта мәктәпне тәмамлаучы байтак яшьләр колхоз стипендиаты булып, республика техникумнарында һәм ВУЗларда белем алдылар. Тора-бара үзләре колхоз-совхоз җитәкчеләре булдылар. Хәер, аның

исәбендәге игелекле эшләрне санап бетерерлек түгел. Һәрвакыт шаян һәм тапкыр сүзле Баян Вәлиевич пенсия яшенә җиткәннән соң да 9 елдан артык колхоз белән җитәкчелек итте. Эштән туктагач та яшьләр белән, мәктәп белән элемтәсен өзмәде. Үзенең күргәннәре, белгәннәре турында яшь буын белән уртаклашты. 1992 елны Баян Вәлиевич вафат булгач, аны Турай авылы зиратына абыйсы белән рәттән җирлиләр.

Азин Нуриәхмәт Хаҗиевич Татарстан Республикасының атказанган механизаторы:

Минем эш стажым 60 елдан артык. Бишенче классны укый башлагач, ике ай чамасы мәктәпкә йөрдем дә, укуымны ташлап көтү көтәргә кердем. Баян Вәлиевич безнең колхозга эшкә килгәндә, мин әле терлекчелектә эшли идем. Ул килгәч колхозга автомашиналар, тракторлар кайтарта башлады. Плугарь булып, тракторчыларга ремонт вакытында булышып йөри торгач, үзем тракторчы булып киттем. Беркайда да укырга туры килмәде дисәм, дөрес үк булмас. Язгы кыр эшләре алдыннан 40 сәгатьлек программаны 20 сәгатьтә укыттылар да, укыды дип документ язып бирделәр. Мин шул документ белән 38 ел тракторларда һәм комбайннарда эшләдем. Язгы кыр эшләре башланганда миңа беренче тапкыр күп еллар эшләгән иске трактор бирделәр. Яшь кешегә, өйрәнчеккә ярар, дигәннәрдер. Иске трактор озак

эшли алмады, ватылып чыкты. Кичкә таба двигателе шакыды. Мин аны берүзем сүтеп, икенче коленвал куеп иртә беләнгә җыеп басуга чыктым. Язгы чәчү барышында трактор тагын да берничә тапкыр ватылса да, таңга кадәр ремонтлап бетерә торган идем. Берничә ел шулай иске трактор белән эшләп язгы чәчү нәтиҗәләре буенча беренчелекне бирмәгәч, Баян Вәлиевич миңа карата бөтен фикерләрен үзгәртте, һәрьяклап булыша башлады. Ул эшләгән кешенең кадерен белә иде. Миңа яңа трактор биргәч тагын дә дәртләнеп эшли башладым. Берничә сезон эшләгәч, Баян Вәлиевич миңа тагын яңа трактор бирде. Башка тракторчылар, ни өчен Нуриәхмәткә генә була яңа тракторлар дип сорагач, ул бит завод эшләп бетермәгән җитешсезлекләрен көйләп бетереп, “обкатать” итеп бирә сезгә, шатланырга гына кирәк, дип авызларын яба иде. Мин язгы кыр эшләре вакытында ДТ -75 тракторы белән һәр елны чәчү чәчтем. Баян Вәлиевичны бик вакчыл, төпченеп берәр гаеп тапмый калмас дисәләр дә, мин чәчкән җирләрне бармагы белән актарып караса да, аннан начар сүзләр ишетергә туры килмәде. Шуның өчендер инде, район үзәгендә

булган, Казанда узган бәйрәмнәргә баручы делегатлардан беркайчан да калдырмады.

Безнең колхозда беренче булып оештырылган хатын-кызлардан торган тракторчылар бригадасының даны еракларга таралган булса да, чылбырлы тракторларда эшләгән механизаторлар да алардан калышмадылар. Ясәвиев Нургали, Гыйльфанов Фәйзелхак, Гыйльфанов Фәйзрахман, Ефимов Александр үзләренең тырышып эшләүләре белән колхозыбызны алга таба алып бардылар. Баян Вәлиевичка безнең колхозда эшләү җиңел булмады. Торакторчылыкка укытып, эшләргә өйрәтеп бетергәч, аларны нефтьчеләр, яхшы хезмәт хакы түлибез, торырга урын бирәбез дип юмалап, колхозны ташлап китәргә мәҗбүр итәләр иде. Яз көннәрендә трактор белән чәчү чәчсәм, көз көне комбайн штурвалы артына утырырга туры килә иде. Комбайнда эшләгәндә дә сынатмадык. Көннәр буе эшләгәндә икешәр бак ягулык бетерә идек. Безнең колхоз басуларында булган кадәр баганалар башка колхоз басуларында булмагандыр.

Чәчү чәчкән вакытларда баганаларны урап үткәч, арттан аерым агрегатлар белән багана төпләрен эшкәртеп бара иделәр. Урып-җыю

чорында артка чигенеп һәр багана саен кул белән йолкып, комбайнның “жатка”сына ташлап йөргән чаклар күп булды. Комбайнчылар – Җиһаншин Габделхәй, Сибгатуллин Галиәхмәт һәм башка комбайнчылар белән эшләү дәверендә Баян Вәлиевич һәрвакыт безнең янга килеп йөрде. Эшләгән эшләребезнең нәтиҗәләре буенча дәүләтебез безне орден-медальләр белән бүләкләде. Баян Вәлиевичның Бәзәкә авылына эшләгән яхшылыклары һич кенә дә онытырлык түгел.

Зоя Семёновна Тарасова – Татарстан Республикасының атказанган агрономы:

Тормыш юлымны “Сталин” корлхозында төрле эшләрдә эшләп башларга туры килде. Кулымда көрәк тә, сәнәк тә, тимер лом да булды. Ир-атлар эшли торган эшләрдә дә эшләдем. Колхозда булган барлык эшләрдә дә катнашырга тырыштым. Гаиләне туйдырырга кирәк иде. Баян Вәлиевич безнең колхозга килеп эшли башлаган вакытта терлек фермаларының гына түгел, икмәк саклый торган амбарларның да түбәләре дә салам белән капланган иде.

Яңа җитәкче килгәч, берләшкән авылларның һәрберсендә икмәкләрне саклау, яхшы орлыклар чәчеп мул итеп уңыш үстерү өстендә эшли башлады.

Авылларда белгечләр җитми иде. Безнең хуҗалыкны районда орлык әзерли торган хуҗалык итмәкче булдылар. Миңа – күп балалы хатынга, укырга керергә тәкъдим ясалды. Мин 1970 еллар башында Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумына читтән торып укырга кердем. 1975 елны 4 баламны өйдә калдырып техникумда имтиханнарны тапшырып, диплом алып кайткач колхозыбызда агроном-семеновод булып эшли башладым. Баштагы мәлләрдә кайларга гына орлыклар эзләп барырга туры килмәде. Татарстанда гына түгел, башка өлкәләргә, республикаларга барып соранып йөрергә туры килде.

Баян Вәлиевич бик таләпчән, бер әйткән сүзеннән кире кайтмый торган җитәкче иде. Аның приказларын үтәмәгән кешеләр белән ул ике тапкыр сөйләшергә яратмады. Шуңа күрәдер мөгаен, колхоздагы эшләр, кыска гына вакытта алга таба киттеләр. Супер-элита, элита, яхшы репродукцияле орлыклар артыннан Столбищега, Сабага, Актаныш, Мөслим районнарына күп тапкырлар орлык алмаштырырга барырга туры килде. Хатын-кыз башыма, ГАЗ -51 машинасы белән, пычракта, өстән яңгыр явып торганда, орлыкка дип барган авыл

янында төнге сәгать 11 дә батып ятып, авылдагы механизаторларны уятып, тирес түгә торган тракторны кузгатып тарттырып чыгарырга туры килде. Баян Вәлиевичның приказлары бушка китмәде, бергәләп тырышкач нәтиҗәләр күзгә күренеп үсә башлады. Районда иң беренчеләрдән булып, Башкортстанга, Стәрлетамакка барып биек үсми, мул уңыш бирә торган арыш орлыгын алып кайтып чәчкәч, беренче елында ук гектарыннан 45 центнер уңыш бирде. Арыш орлыгын башка хуҗалыкларга сатып бирә башлагач безне санлый башладылар. Башка объектлар төзү өчен акча барлыкка килде. Игенчелектә шактый гына алга китеш булса да, техник культураларга килгәндә, безнең җитешмәгән эшләребез дә бар иде. Баян Вәлиевич үзенең авторитеты белән күпме генә тырышса да, киметергә йөрсә дә, һич кенә дә булдыра алмаган эше - бәрәңге игү буенча колхозга җиткерелгән бәрәңге утырту планы. Безгә беренчеләрдән булып “Невский” дигән яңа сорт бәрәңге кайтарттылар. 260 гектар бәрәңге утырту планы җиткерелде. Ул бәрәңге белән чиләнүләрне бүгенгесе көннәрдә дә һич кенә онытырлык түгел. Авыл халкы, мәктәп балалары, Менделеевск

шәһәрендә булган оешмалар, хәтта Алабугадан милиция курсантлары килсә дә, ап-ак карлар яуганчы бәрәңге алу белән чиләндек. 1980-1981 елларда колхозларда яңа система җир эшкәртү буенча алга таба планнар төзелде. Яңа җир әйләнеше кертелде. Боларны тормышка ашырганда безгә комачаулый торган фактлар да аз түгел иде. Боларның берсе – Бәзәкә, Сәйтәк авыллары тирәсендә нефтьчеләрнең, электрикларның объектлары. Басуларда меңләгән баганалар, качалкалар, будкалар, вышкалар һәм комачаулый торган башка нәрсәләр булу нәтиҗәсендә күп югалтуларга дучар булдык. Халык телендә шул баганалар яфрак ярсалар, бу җирләрдә күптән урман булыр иде, дигән сүзләр барлыкка килде. Баян Вәлиевич чәчү чәчкәндә, куелган нормадан тыш чәчелгән орлыклар өчен утлы табага бастыра иде. Башка колхозларның “симәнәсе” дөрес керә, норма буенча, ә “Кама” колхозында артык керә. Баян Вәлиевич Сталин чорында эшләгән кеше буларак төгәллекне ярата. Әмма меңләгән баганалар арасыннан боргаланып йөреп “перерасход”сыз эшләп булмады.

Бәзәкә авылында хатын-кызлардан төзелгән механикалаштырылган бригада үзебез өчен бик тә яхшы булды. Ферма тирәсендә булган барлык тиресләрне вакытында чыгарып, яхшы иттереп пар җирләрен эшкәртеп торганга, арыш, көзге бодай культуралары мул уңыш бирделәр. Урып-җыю чорында терлекләргә сусыл азыклар ташыганда ул отрядның колхозга файдасы бик зур булды. Кукурузны, бәрәңгене, чөгендерләрне эшкәртү буенча колхозда звенолар төзелде. Звеноводлар – Ефимов Александр, Попов Василий, Низаметдинов Фәттах, Нуриев Миңневәҗитләр район буенча алдынгылыкны бирмичә тырышып эшләделәр. Авыр еллар да безне читләтеп үтмәделәр. 1981 елны булган корылык вакытында икмәкләр куырылып бетте. Ул елны 12 июльгә, беренче тапкыр, кибеп беткән арыш амбарларга кайтты. Терлекләргә ашатырга саламнар булмады. Чит өлкәләргә барып салам алып кайтырга туры килде.

Урып-җыю чорында эшләгән механизаторлар хөрмәткә лаек булдылар Азин Нуриәхмәт, Шишкин Михаил, Куршаков Николай, Чукин Александр һәм башкалар. Баян Вәлиевич эшләгән кешеләрне хөрмәт итә белде, ялкауларга түзмәде. Колхозга

килгән яшь белгечләр арасында авыл хуҗалыгы буенча белеме булмаган килеш ничек эшләрне алып бара икән дигән сорау туа...

Баян Вәлиевичның энергиясе, эшне оештыра белүе, таләпчәнлеге, ничә еллар буена мәктәпләрдә, сугышта җыелган тәҗрибәсе мин белемле дип йөргән кешеләрдән күпкә артык иде.

Маннапов Ромель Зөфәрович – ТР атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре:

Мин Баян Вәлиевич Әхмеровны малай чагымнан ук беләм. Аның хатыны – Бәдәр апа Балтач авылыныкы булганга күрә, алар Балтачка еш кунакка киләләр иде. 1933 елны Баян абый белән Бәдәр апа Балтач авыл Советында язылышканда минем бабам Хикмәтулла Маннапов колхоз рәисе булып эшли торган була. Баян Вәлиевич белән минем бабам бер-берсен бик яхшы белгәннәр һәм һәрвакыт элемтәдә торганнар. Сугыштан соңгы чорда Баян Вәлиевичны Бәзәкәгә колхоз рәисе итеп җибәргәндә, сугыштан кайткан минем әтине дә Балтач авылына рәис итеп куялар. Алар һәрвакыт очрашып сөйләшә торган иделәр. Безнең авыл халкы йомыш белән Алабугага, Казанга барганда берәр мәшәкать чыгып трактор яисә машиналары ватылса, юлларны бураннар капласа, кунарга урын эзләп, хәтта кешеләрнең юлда

акчалары беткән чакларда Баян Вәлиевич янына кергәч, ул аларга һәрвакыт булыша торган булган. 1961 еллар башында Бондюг, Красный Бор, Әгерҗе районнарын берләштереп Алабуга районына кушкач, бер районда яши башлагач авыллар арасында мөнәсәбәтләр тагын да ныгый. Алабуганың көньяк-көнчыгыш ягында 5 колхоздан торган район картасында йолдыз шикелле формада урнашкан бик көчле хуҗалыклар барлыкка килә.

1. Салагыш авылы – Пушкин ис. колхоз, рәисе - Исмәгыйлев Хәмәт Фәссахович
2. Балтач авылы – Жданов ис.колхоз, рәисе - Маннапов Зөфәр Хикмәтович
3. Турай авылы - “Кызыл Май” колхозы, рәисе - Абдуллин Нурулла Абдуллович
4. Песәй авылы –“Кызыл Йолдыз” колхозы, рәисе - Латыйпов Мәүҗит Латыйпович
5. Бәзәкә авылы – Сталин ис.колхоз, рәисе - Әхмеров Баян Әхмерович

Бу хуҗалыкларның рәисләре бер-берсе белән бик нык дуслашалар. Бер-берсен уздырырга дип, ярышып эшли башлыйлар. Бу булдыклы егетләрнең командирлары Әхмеров Баян

Вәлиевич була. Ул алардан 13-16 яшькә зуррак булуга карамастан, утка күмер өстәгәндәй, һәрвакыт яңалыклар уйлап табып, аларны котыртып, эштәге нәтиҗәләрен арттыруга таба алып бара. Безнең авыл кешеләре кышкы салкын көннәрдә ДТ-54 тракторына тагылган агач чанага салган салам өстенә утырып, өсләренә толып киеп, Алабугага райком бюросына яисә җыелышларга барганда, кайтканда юл өстендә булган Бәзәкә авылында туктала торган булганнар. Баян Вәлиевичны, үзебезнең якын кеше бит ул диеп, Бәзәкә авылындагы идарә йортына туктап, җылынып чыгу гадәткә кереп киткән. Сессиягә барган депутатлар, семинарларда катнашкан белгечләр авылга кайткач, һәрвакыт мактала торган колхоз рәисе Әхмеров Баян Вәлиевич турында халыкка сөйли торган булганнар. Әгерҗе районын Алабуга районыннан аерып алгач та, моңарчы барлыкка килгән дуслык колхозлар һәм хезмәткәрләр арасында озак еллар дәверендә сакланды.

1977 елны Казан авыл хуҗалыгы институтында укыганда, җәйге практикага үз теләгем белән, Бәзәкә авылына кайттым. Студент

буларак, көн саен эшләгән эшләр турында көндәлек дәфтәргә мәгълүматлар язып барырга кирәк иде. Баян Вәлиевич бик кырыс кеше иде. Белгечләр аның күз карашыннан курыктылар. Ул бер сүз эндәшмичә күзе белән йөртеп чыкканда, кайчакларда бала йоннары кабара иде. Гаепсезгә бәйләнмәде, булдырган кешегә рәхмәт әйтә белде дип, эшкә башлаган көннәремдә язып куйганмын.

Баян Вәлиевич эшкә иртәнге алтыдан соңга калмыйча килеп җитә торган иде. Көндезге икедә белгечләрне җыеп, эшләгән эшләргә нәтиҗә ясады. Кабинетта озын өстәл артында һәр белгечнең үзенең урыны булды. Баян Вәлиевичның уң ягында иң якын кешесе булып, Сталин колхозын оештырганда 14 яшендә беренче протоколын язып башлаган Габделхак Гыйльфанов утырды. Аның белән рәттән Сәйтәк бригадасы бригадасы бригадиры Александр Миронов. Миронов каршында Бәзәкә авылы бригадиры Мулланур абый Фәссахов, аның янында агроном Әсгать Гыйльметдинов. А. Миронов янында Зоя Семёновна Тарасова, аның белән рәттән зоотехник Хәбибуллина Фәрдәвия

утырдылар. Зәки абый белән, Тәкәштән Тәлгать абыйның, урыннары арттарак иде. Мин практикант кына булганга, арттагы буш урынга гына барып утырдым. Баян Вәлиевич мине күргәч, кулы белән генә чакырып алды да, иң алдагы урындыкка утырырга кушты һәм әйтеп куйды: басу буйлап чабып йөрергә артык акыл кирәкми, кеше белән эшләргә өйрәнү өчен тыңлый белергә дә кирәк, диде. Мин тып-тын калдым, үземне мәктәптә укый торган бәләкәй малай кебек хис иттем. Баян Вәлиевич мине кечкенә чактан ук белгәнгә күрә, үз малае шикелле кабул итте. Әмма ләкин, эш турында сүз кузгалганда ул кисәк кенә хәрби кешегә әйләнә торган иде. Яңалыклар турында сөйләгәндә, алга таба бурычлар куйганда ул укытучы булды. Шулай бервакыт икебез генә калган чакта, мин Баян Вәлиевичтан сорадым, нигә сез Бәзәкәгә йорт салмадыгыз, нигә авылда тормыйсыз, дип. Ул миңа таба борылды да җитди йөз белән җавап бирде: беренчедән, җиде яшемнән авылдан - авылга, шәһәрдән – шәһәргә, хәрби частьтан-хәрби частька күченеп йөрү туйдырды инде. Икенчедән, колхоз рәисенең эш урыны шундый

урын ул, бүген эшлисең шул эштә, иртәгесе көнне сине юк итәргә мөмкиннәр, рисковать итәсе килмәде, мин сапёр кеше бит дип, көлемсерәп җавап бирде.

1977 елның 1 маена “Кама” колхозында язгы кыр эшләре тәмамланды. Сентябрь азагына көзге урып-җыю эшләре дә әйбәт кенә бетте. Институтта бирелмәгән белемнәрне, “Бәзәкә” авылында эшләгәндә, укытучы Баян Вәлиевичтан алган тормыш белемнәре өчен, мин бүгенгесе көндә дә аңа рәхмәтле.

Нәбиуллина Сания Миңнерәхмановна:

Бик яшьли, хезмәт көненә колхозда сыер сава башладым. 40 елдан артык гомеремне колхозда сыер савып үткәрдем.

Әхмеров Баян Вәлиевич Бәзәкәгә килеп, колхоз рәисе булып эшли башлаганда, мин алдынгы сыер савучыларның берсе булып җитешкән идем инде. Ул беренче тапкыр сыер савучылар янына килгәч, без яшь кызлар үзара елмаешып–көлешеп куйдык. Ишетеп белүебез буенча, ул бер көн дә авыл хуҗалыгында эшләмәгән, укытучы булып балалар укыткан. Армиядә хезмәт иткән кеше нәрсә белә икән сыер турында, диеп куйдык. Исәнмесез кызлар, диеп елмаеп килеп кергәч, без, Аллага шөкер, диеп җавап бирдек. Мине сыер саварга өйрәтәсезме дигәч, без аптырашта калдык. Әхмеровка кадәр булган колхоз рәисләре алай сөйләшми иделәр.

Тора-бара Әхмеров та үзгәрде. Ярты елдан соң, әллә кайлардан аның машинасы күренүгә,

сыер савучылар кырмыска оясындагы шикелле тыз-быз чаба башлый торган иделәр. Ул елларны бер сыердан савып алган сөт 2000 литр булса, зур күрсәткеч булып саналды. Фермалар иске, түбәләре салам белән ябылган. Кайсыбер елны язга чыкканчы, түбәдәге саламны малга ашатып бетерә торган идек. Басулардан җыеп алынган икмәкләрнең күбесен дәүләт алып бетерде. Җитмәсә, халыкка яшәр өчен хезмәт көненә дә икмәкләтә биргәнгә күрә, сыерларга, башка малларга азык бик аз тиде. Баян Вәлиевич эшли башлаган елларда кукуруз игә башладылар, турнепс утырттылар, күп еллык үләннәр чәчтеләр, шуңа күрә сөтләр дә арта башлады. Әхмеров фермаларны яңартты, нәселле таналар кайтартты, саламны турап бирә башладык. Басуларда икмәк уңышы арта башлагач, буаз сыерларга солы пешердек. Кормоцехлар барлыкка килде. Төннәр буе бәрәңге пешерә торганнар иде. Шулай булуга карамастан, районда узган җыелышлардан кайтканда идарәгә кермичә, рәис туп-туры фермага килгәндә, безнең котлар очып тора иде. Без фермада эшләгән чорда коллективыбыз бик әйбәт иде.

Минем белән бергә, Закирова Гөлнәфис, Миңнәхмәтова Миңниса, Закирова Сания, Сабитова Хәлимәләр һәм башка хатын-кызлар эшләделәр. Сыерларны тукландыручылар, җәйләрен көтү көткән ир-атлар - Әхмәтшин Галиәхмәт, Гайнуллин Гәрәй, Сәлимуллин Миңнегали, Галиев Сәетгали, Гәрәев Габдулла һәм башкалар булдылар. Ферма җитәкчеләре булып Бикмөхәммәтова Нажия, Фәтхуллин Нуриәхмәт, Нәбиуллин Габделхәйләр эшләде. Ферма җитәкчеләре нәрәткә дип идарәгә Баян Вәлиевич янына бара торган иделәр Аннан кып-кызыл булып безнең янга кайткач, безгә дә матур сүзләр эләгә торган иде. Фермалардан сөт җыюны Бикмөхәммәтов Дәүләт башкарды. Мал табибы булып бик озак еллар, таләпчән кеше Нәбиуллин Ясәви эшләде. Авыр еллар аша үтәргә туры килде. Баштагы мәлләрдә өскә кияргә дә, аякка кияргә дә булмады. Сыерны башка кешегә калдырсаң, сыер бозыла, сөт кими дип елның бер көнен дә калдырмыйча эшләдек тә, эшләдек. Баян Вәлиевичның да хезмәтләре бушка китмәде, елдан-ел тормыш үзгәрде, алга таба барды.

Шундый булмаса, аны 25 елдан артык шул эштә тотмаслар иде.

Хуҗахмәтов Мансур Мөхәммәтдинович.

Мәктәпне укып бетергәч, читкә китәргә дип уйлап, паспорт сорап Баян Вәлиевич янына кердем. Аның кабинетына керергә кешеләр калтыранып чират көтеп торалар иде. Мин кереп берничә сүз әйтүгә, ул мине туктатты да әйтте: “Син авылда туган малай, авылда калырга тиеш” – дип. Шуннан соң мин бер сүз дә каршы әйтмичә, борылып чыгып киттем дә, фермада кочегар булып эшкә ябыштым. Шоферлыкка укып таныклык алгач, армия сафларына җибәрделәр. Хезмәтемне тутырып кире авылга кайткач, читкә китәргә дигән уйлар кимегән иде инде, һәм мин колхозда шофер булып эшкә керештем. Баян Вәлиевич эштән туктаганчы, 15 ел гомер дәверендә аның кул астында эшләргә туры килде. Ул заманнарда шофер һөнәре мактаулы

һөнәр иде. Эшли башлаган яшьләргә шоферлар үзләре, чиратка салып, эштә кулланылган машиналарны бирә торганнар иде. Миңа ГАЗ-63, ГАЗ-51,52,53 маркалы машиналарда һәм сөт ташу машинасында эшләргә туры килде. Ялны, якшәмбене белмәдек, кайда кушсалар шунда бардык. Баян Вәлиевич эшләгән кешене күрә белә иде. Кеше сүзенә ышанып кына, колхозда җаваплы эшләргә теләсә кемне куймады. Үзенең күз алдында эшләп, нәтиҗәле хезмәт күрсәткән кешеләргә генә ышанды. Армия сафларыннан кайтып, ике ел шофер булып эшләгәч, Баян Вәлиевич мине Бәзәкә авылына комплекслы бригаданың бригадиры итеп куйды. Ул эштә мин 1976 елга кадәр эшләдем. Колхозга яңа техникалар, автомашиналар кайта башлагач, Бәзәкәдәге төп гаражга мөдир итеп күчерделәр.

Баян Вәлиевич Бәзәкәгә килеп эшли башлагач, фермалар төзүдән тыш, колхозда яңа гараж, ягулык-майлау пунктлары төзетте. Якын тирәләрдә нефтяниклар, энергетиклар күп урнашу сәбәпле, аларда хезмәт хакы колхоз белән чагыштырганда бермә-бер артык булганга күрә, техникада, техника белән эшләүче белгечләр җитмәде. Баян Вәлиевич

сугышта күпне күргәнгәме, тегесе юк, монысы юк, дип зарлана торган кеше түгел иде. Ул бервакытта да югалып калмады. Без дә аңарга охшарга тырышып эшли идек. Гараж мөдире дисәм дә, машиналарны ремонтлау буенча шоферлар белән бергәләп, барлык слесарь эшләрен дә үзебезгә эшләргә туры килде. Тишелеп кайткан тәгәрмәчләрне ямау, рессорлар алмаштыру гына түгел, автомобильләрнең двигательләрен сүтеп җыеп, коленвалларны эшкәртеп, клапаннарны дөресләп кую да безнең өстә иде. Үзем аккумуляторчы та идем. Бөтен авыл кешеләренең мотоцикл аккумуляторларын тикшереп тәртиптә тоту да минем өстә булды. “Ничек тешләр коелып бетмәгән аккумуляторныйда кислота исе иснәп?!”

Баян Вәлиевич үзе бервакытта да машина руле артына утырып йөрмәде. Идарә утырышы белән расланган штаттагы шофер йөртте аны. Бигрәк тә, җәйге чорда, язгы чорда, печән өсте, урып-җыю вакытларында кеше җитмәү сәбәпле, ул үзен йөртә торган шоферын башка эшләргә куша торган иде. Кисәк кенә берәр эш килеп чыкканда, мин һәрвакыт машиналар гаражында булганга күрә, үзенең машинасының руле артына мине дә утыртты. Эшләү

дәверендә аның белән кайларда гына булмадык, кемнәр белән генә очрашмадык. Хәтеремдә калган мизгелләрнең берсе: чәчкән икмәк өстеннән рөхсәтсез нефтяникларның күчерә торган вышкасы янына килеп туктагач, Баян Вәлиевич трактористны чакырып китерде дә, урысча иттереп: “Кто приказал?” – диде. Мастерның фамилиясен ишеткәч, аны рациядән чакырттырып китереп, бик каты итеп сөйләшкәннән соң, без машинага утырып райкомга киттек. Баян Вәлиевич юл буе үзалдына нидер сөйләнеп барды. Мин аның сүзләренең берничә җөмләсен генә ишетеп калдым: “Бәхетегездән мыек исән түгел, күрсәтер иде ул сезгә икмәк өстеннән ничек йөрергә икәнен, ятар идегез Себердә сохари суырып”.

Баян Вәлиевичның соңгы эш көнендә миңа тагын аның машинасының руле артында булырга туры килде. Без көне буе нефтяниклар тирәсендә, ул төзетә башлаган сарык абзарының утарын тотар өчен торбалар эзләп йөрдек. Мин шул вакыт батырчылык итеп Баян Вәлиевичтан сорадым: “Баян абый, Сезне эштән китә диләр, нигә китәсез?” – дип. “Арыдым инде, улым, арыдым” – диде.

Аглиев Зайнак Аглиевич, Бөек Ватан сугышы ветераны, РСФСРның мәгариф отличнигы

Каһәрләнгән сугыш зәхмәтләре безне – әле балигъ булмаган яшь буынны да читләтеп үтмәде. 1944 елны 17 яшемдә туган авылым Бәзәкәдән сугышка дип алып киттеләр. Балтыйк диңгезе буенда фашистлар яклы булган адәм затларына каршы сугышырга туры килде. Безнең чор малайларының шактые шул Балтыйк җирләрендә мәңге ятып калдылар. Сугыш бетте диеп, илебез халкы 9 май – Җиңү бәйрәмен үткәргәннән соң да әле шактый вакытлар дошман яклы булган кешеләргә каршы сугыш дәвам итте. 1946 елны Япон милитаристларына каршы көрәшергә диеп, Ерак Көнчыгышка җибәрделәр. Юлда барганда, Түбән Тагил шәһәрендә туктатып, гаскәрләребезне тулылындыру йөзеннән, анда

укырга һәм хезмәт итәргә туры килде. Пермь шәһәрендә кыска вакытлы курсларда укытып, офицер чины биреп, безне Ерак Көнчыгыш фронтына алып барып җиткерделәр. Шактый еллар шунда хезмәт иттем, күрмәгәннәр калмады. 1952 елны җир тетрәү аркасында океанда цунами барлыкка килеп, 35 меңләп халкы булган шәһәрне океан суы каплады, нибарысы 2-3 мең кешесе калды. Көч-хәл белән генә котылдык. Ул якларда тынычлык урнашкач, кире Пермь шәһәренә кайтып, хәрби заводта хезмәт итүемне дәвам иттем.

1954 елны туган авылыма кайтып, мәктәпкә эшкә кердем. 1956 елны Казан Дәүләт университетының механика-математика факультетына укырга кердем. Беренче курсны бетергәннән соң, авариягә эләгеп, шактый гына вакыт больницаларда ятарга туры килде. Терелеп чыканнан соң, читтән торып география факультетына күчеп укып бетердем.

1958 елны Баян Вәлиевич Бәзәкәгә эшкә килгәндә, мин кечке мәктәптә 5-7 сыйныфларда математика, өлкән сыйныфларда физкультура укыта идем. Без, 2 сугыш ветераны, ике офицер, бер-

беребезне бик тиз аңлашып, матур гына эшләп киттек. Ул чорларда мәктәпләр белән колхозлар зур бәйләнештә иделәр. Укытучылар колхозларның һәр тармагында диярлек катнашып, илебезнең икътисадын үстерүдә бик күп көч куйдылар. Колхозлар да, мөмкинлекләреннән чыгып, мәктәпләргә булыштылар. Миңа Бәзәкә авыл советы җирлегендәге колхоз партия оешмасы секретаренең ярдәмчесе булып, идеология һәм пропаганда эшләрен шактый еллар алып барырга туры килде.

Язгы кыр эшләре вакытында, урып-җыю чорында, кышкы көннәрдә – терлекчелек фермаларында, мәктәптә эшләр беткәннән соң, көнне-көнгә ялгап, бушлай эшләргә туры килде. Баян Вәлиевич үткәрә торган идарә утырышларында, колхоз җыелышларында катнашып, халыкка Партия съездлары, конференцияләрне җиткердек, алга таба бурычлар куйдык, агитация эшен алып бардык, стенгазеталар чыгардык. Тәртип бозган очракларда, партия әгъзаларын партҗыелышларда тикшереп, чаралар күрдек.

1965 елны мине күрше Турай авылына мәктәп директоры итеп билгеләделәр, анда 7 ел эшләдем.

1972 елны мине перевод белән Бәзәкәгә мәктәпкә директорның тәрбия эшләре буенча ярдәмчесе итеп куйдылар. Эшләү дәверендә мин завуч та, мәктәп директоры да булдым.

Баян Вәлиевич белән без һәрвакыт уртак тел табып эшләдек. Мәктәптә тәҗрибә-өйрәнү бригадасы оештырылды. Ул бригада колхоз белән элемтәдә торып, бик күп эшләр башкарды. 60нчы еллар башында Н.С.Хрущев илебезгә кукуруза үстерүне керткәч, без мәктәп балалары белән квадратно-гнездовой алымнарны кулланып, классларда кукуруза үсентеләрен помидор үсентеләре шикелле үстереп, тәҗрибә участокларында һәм колхоз басуларында игеп, зур уңышларга ирештек. Мәктәп балалары белән Мәскәүгә ВДНХга бардык – бүләкләр алдык. Колхозда үстерә торган 260 га бәрәңгенең 150 га безнең мәктәп карамагында була торган иде. Күп еллар борчак үстерү буенча алдынгы алымнарны кулланып, Республика дәрәҗәсендә зур уңышларга ирештек, Мактау грамоталарына, кыйммәтле бүләкләргә лаек булдык. Терлекләргә чөгендер үстерүдә фәнгә нигезләнеп, төрле алымнар

кулланып, тәҗрибә участокларындагы мәгълүматларны фәнни журналга язып чыктык. Мәктәп балалары белән бәрәңге ямнарына бәрәңге шытыгы сындырырга йөрдек, утыртыр алдыннан – бәрәңге ярдык. Халыктан көл җыйдык. Тавык, сарык фермаларын чистарттык. Эшләмәгән эш калмады.

Баян Вәлиевич үзе укытучы, мәктәп директоры булып эшләгәнгәме, укытучылар белән һәрвакыт элемтәдә торды. Аның кырыслыгы да, хәйләкәрлеге дә бар иде. Ул, бернинди каршылыкларга карамастан, үзе уйлаган эшне һәрвакыт җиренә җиткермичә туктамады. Шуның аркасында район белгечләре белән каршылыкларга очраган вакытлары аз булмады. Уйлаган эшләре аныңча барып чыккач, елмая торган иде. Райондагы яшь белгечләр Баян Вәлиевичның хаклы икәнен аңлагач, аңа артык сүз әйтмәделәр, әмма ләкин аяк чалучылар булмады түгел – булды. Үзенә ошамаган белгечләр турында ул хурлап сөйләмәде, киресенчә, мактый иде. Баян Вәлиевич белгечне мактагач, өстәге җитәкчеләр аның авторитетына таянып, ул белмичә әйтмәс диеп, белгечне башка урынга

күчереп куя иделәр дә, Баян Вәлиевич алардан котыла иде.

Бәзәкәдә 60 яшьлек юбилеен зур күләмдә үткәрергә җыенганда, ниндидер сәбәп табып, аны үткәрми калдылар. Без партия оешма секретаре белән икебез аның өенә барып котладык. Шуннан соң да әле ул бирешмәде, яңадан 9 ел җитәкче булып эшләвен дәвам итте.

Мин инде хәзер 90 яшьне уздым, ул еллардан соң күп сулар акты. Элек эшләгән чорларны искә алам. Баян Вәлиевич искә төшә. Авторитетлы кеше иде, Бәзәкәне бик нык яратты!

Дәүләтебез Баян Вәлиевичның хезмәтләрен югары бәяләде:

1. 1954 – “Орден Красной звезды”
2. 1966 – Орден “Знака Почета”
3. 1971 – Орден “Октябрьской революции”
4. 1985 – Орден “Великой Отечественной войны 2 степени”
5. 1964, 1983 – Почётная грамота Президиума Верховного Совета ТАССР
6. Почётная грамота Елабужского горкома КПСС и исполкома районного Совета народных депутатов
7. 1964 – Свидетельство о занесении в книгу Почёта Дома Политического Просвещения Татарского обкома и Казанского горкома КПСС
8. 1962 – Медаль “За оборону Киева”
9. 1967 – Медаль “Двадцать лет Победы в Великой Отечественной войне”
10. 1970 – Медаль “За доблестный труд”
11. 1973 – “Победитель Социалистического соревнования”
12. 1976 – Медаль “Ветеран труда”

13. 1975 –Медаль “Тридцать лет Победы” в Великой Отечественной войне
14.1979 – Медаль “60 лет Вооруженных сил СССР”
15.1985 – Медаль “40 лет Победы в Великой Отечественной войне”
16. 1989 – Медаль “70 лет Вооружённых Сил СССР

- сугыш вакытында Баян Вәлиевичның күрсәткән батырлыклары өчен бирелгән медальләре турында алдагы битләрдә язылып китте.

Язлар җитеп карлар эри башлагач, эрегән кар сулары гөрләвекләр булып чокырларга, ермакларга ыргылалар. Бәзәкә авылының кар сулары Кама елгасына барып тоташа. Алга таба су юлы буйлап, Турай авылының болыннарын урап, Салагыш авылының текә ярларына бәрелеп, Актаныш якларынан килгән суларга кушылып китәләр. Еллар узган саен бу хәлләр кабатланып тора. Карлар күпме генә эреп акмасын, нинди көчле яңгырлар явып үтмәсен, алар һич кенә дә Бәзәкәдә Баян Вәлиевич калдырган эзләрне юып бетерә алмыйлар.

Сугыштан соң үзенең бөтен гомерен Бәзәкә халкына багышлаган Баян Вәлиевич турындагы хатирәләр тирән эзләр булып хәтерләрдә саклананалар.

Турай авылы зиратыннан яңгырдан соң пар күтәрелгәндә, бу табигый хәлгә бу зиратта булган ике кабер өстендәгеләр дә кушыла. Бу ике кабер Габделвәли абзыйның беренче һәм икенче малайлары – Миргалим белән Фәтхелбаяннныкы. Пар булып күтәрелеп һавадагы болытларга

җитәләр дә, Актаныш ягына таба агалар. Күҗәкә авылы турысына җиткәч, үзләренең кендек каннары тамган җиргә тамчы булып тамалар.

Баян Вәлиевичның туганнары һәм аларның балалары турында

“Актаныш таңнары газетасының 2012 ел 22 июнь санында басылган Әхмеровлар буыны дигән материалдан алынган.

Габделвәли байның балалары:

1. Миргалим Әхмеров
2. Фәтхелбаян Әхмеров
3. Мәрьям Әхмерова
4. Мәгъфүрә Әхмерова
5. Нурлыгаян Әхмеров
6. Фарсый Әхмеров
7. Мөхтәр Әхмеров
8. Назыйм Әхмеров
9. Әхмәтзыя Әхмеров

Миргалимнән туганнар:

1. Рәсим
2. Реваль
3. Ринас

4. Илгиз
5. Люция
6. Фирдания
7. Гүзәл

Мөхтәрдән туганнар:

1. Вәсил
2. Наил
3. Марсель

Миргалим Вәлиевич Әхмеров 1929 елда Минзәлә педагогия училищесын тәмамлап Турай авылына укытучы булып килә. Шул елдан алып 1941 елга кадәр укытучы булып эшли. 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. Каты яралану сәбәпле 1943 елның мартында яңадан Турайга әйләнеп кайта һәм балаларга белем бирүен дәвам итә. 1953 елга кадәр Турай сигезьеллык мәктәбе директоры булып эшли. 1948-1953 елларда партоешма секретаре булып сайлана. 1951 елда аңа Почет билгесе ордены тапшыралар. 1953 елда Турай авылы “Кызыл май” колхозына рәис итеп билгеләнә. Ул 1960 елга кадәр шул постта эшли. 1964 елга кадәр яңадан Турай мәктәбендә

укыта. Шул елларда аны Турай авыл Советы рәисе итеп сайлыйлар. Пенсиягә чыгар алдыннан ул яңадан укытучы. 8 бала тәрбияләп үстерәләр. Миргалим абыйның Люция исемле кызы тугач аның хатыны чирләп китә. Вафаты алдыннан Баян Вәлиевичның хатыны Бәдәр апага васыять итеп кече кызлары Люцияне тәрбияләп үстерүләрен сорый.

Баян Вәлиевич белән Бәдәр апа Люцияне 3 яшь ярымлык чагыннан алып үстерәләр. Люция институт тәмамлап 40 елдан артык Менделеевск шәһәрендә укытучы булып эшли. Хәзерге вакытта лаеклы ялда.

Мәрьям Вәлиевна Әхмерова. Мирзагабдрахман муллага кияүгә чыга. Гомере барышында абыстай булып яши.

Мәгъфүрә Вәлиева Әхмерова Менделеевск районында укытучы булып эшли.

Нурлыгаян, Фарсый, Мөхтәр Әхмеровлар сугышта һәлак булалар. Назыйм Әхмеров – билгесез. Әхмәтзыя Әхмеровның балалары юк.

Миргалим Әхмеровның балалары:

Рәсим – Казан артиллерия училищесын тәмамлый. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп ялга чыга. Хәзер Киев шәһәрендә яши.

Ринас – диңгез училищесын тәмамлап, күп еллар тыныч диңгез корабларында хезмәт итеп ялга чыга, Владивосток шәһәрендә яши.

Реваль – полковник, юридик фәннәр докторы. Профессор, КФУ ның халыкара һәм Европа хокуклары кафедрасында укыта. 13 ел дәвамында Татарстан Югары Суды әгъзасы, аның Президиум әгъзасы. Казан юридик институтында кафедра җитәкчесе була. Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган юристы.

Илгиз Миргалим улы – физика- математика фәннәре докторы, профессор, Казан энергетика университетында кафедра җитәкли. Татарстан Республикасының атказанган фән һәм техника эшлеклесе. Шотландиядә (Англия) чыккан халыкара энциклопедиядә Ел кешесе дип игълан ителә.

Баян Вәлиевичның туганнары, балалары, аларның балалары турында берничә җөмлә белән генә сөйләп, аңлатып бетерерлек түгел. Алар илебезнең төрле шәһәрләрендә, төрле почмакларында туган илебезгә хезмәт итүләрен дәвам итәләр.

Абыйсы Миргалим Вәлиевич Әхмәров

Баян Вәлиевич, хатыны Бәдәр,
сеңлесе Мәгъфүрә, аның ире Бари

Баян Вәлиевичнең энесе Назыйм

Баян Вәлиевич абыйсы Миргалим һәм туганнары белән